ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 апрель 2018 ел. № 2306

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алучыларга урнашуга рөхсәт бирү тәртибе турындагы нигезнамәне раслау хакында» 2010 елның 26 гыйнварындагы 295 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Шәһәр Уставының 42 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган муниципаль хокукый актлар системасы турындагы нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алучыларга урнашуга рөхсәт бирү тәртибе турындагы нигезнамәне раслау хакында» 2010 елның 26 гыйнварындагы 295 нче карарына (Башкарма комитетның 2010 елның 10 февралендәге 763 нче карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә;

2) 1 пунктның 2, 3, 4 пунктчаларын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 25 апрелендәге
2306 нчы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алучыларга урнашуга рөхсәт бирү тәртибе турында нигезнамә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Яр Чаллы шәһәре муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алучыларга урнашуга рөхсәт бирү тәртибе турында нигезнамә (алга таба – Нигезнамә) Россия Федерациясе Торак кодексы, Шәһәр Советының 2007 елның 4 октябрендәге 25/5 нче карары белән расланган Яр Чаллы шәһәренең муниципаль мөлкәтен биләү, файдалану, аның белән идарә итү һәм эш йөртү тәртибе турындагы нигезнамә, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, Яр Чаллы шәһәренең муниципаль хокукый актлары нигезендә эшләнде.

2. Әлеге Нигезнамә социаль наем килешүләре буенча биләнүче Яр Чаллы шәһәре муниципаль торак фондының торак биналарына наемга алучы белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары, вакытлыча наемга алучылар сыйфатында башка гражданнарны урнаштыруның һәм вакытлыча наемга алучыларны урнаштыру, муниципаль торак фондында вакытлыча яшәүчеләргә яшәү өчен рөхсәт бирүнең бердәм тәртибен билгеләү максатында эшләнде.

3. Социаль наем килешүләре буенча бирелә торган торак биналарны наемга бирүченең вәкаләтләрен Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге исеменнән Башкарма комитет (алга таба – наемга бирүче) гамәлгә ашыра.

4. Наемга алучы – торак бинаны социаль наем килешүе буенча биләүче граждан (алга таба – наемга алучы).

5. Икенчел наемга алучы – наемга бирүче белән торак бинаның икенчел наем килешүен төзүче граждан.

6. Вакытлыча яшәүчеләр – социаль наем килешүе буенча торак бинаны биләүче наемга алучы һәм аның гаилә әгъзалары белән бергә вакытлыча һәм түләүсез яшәүче гражданнар.

2 бүлек. Социаль наем килешүе буенча биләнүче торак бинага наемга алучы тарафыннан үзенең гаилә әгъзалары сыйфатында башка гражданнарны урнаштыру

7. Торак бинаны наемга алучы үз гаиләсе әгъзаларының, шул исәптән гаиләсенең вакытлыча булмаган әгъзаларының һәм наемга бирүченең

рөхсәте белән, социаль наем килешүе буенча үзләре биләгән торак бинага үзе белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары сыйфатында башка гражданнарны урнаштыру хокукына ия. Наемга бирүченең һәм наемга алучы гаиләсенең ризалыгы язма рәвештә рәсмиләштерелә.

8. Социаль наем килешүе буенча биләнүче торак бинага наемга алучының үзе белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары сыйфатында ирен яки хатынын, балаларын, ата-анасын урнаштыру өчен наемга бирүченең ризалыгы таләп ителми.

9. Наемга алучы социаль наем килешүе буенча үзләре биләгән торак бинага үзе белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары сыйфатында башка гражданнарны урнаштырганда, наемга бирүчедән рөхсәт алу зарур.

10. Торак бинаны наемга алучы үзе белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары сыйфатында башка гражданнарны урнаштырырга теләгәндә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсенең торакны үстерү бүлегенә (алга таба – торакны үстерү бүлеге) үзе белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары сыйфатында башка гражданнарны урнаштыруга рөхсәт бирү турында Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә әлеге Нигезнамәнең 1 нче кушымтасында каралган форма буенча гариза тапшыра.

11. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) наемга алучының һәм торак бинада аның белән яшәүче затларның һәм торак бинага урнаштыру турындагы мәсьәләне карауга мөнәсәбәтле гражданның паспорт күчермәләре (торак бинада наемга алучы белән яшәүче ундүрт яшькә кадәрге балигъ булмаганнарның туу турында таныклык күчермәсе);

2) торак бинага социаль наем килешүенең (ордерның) төп нөсхәсе яки законда билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсе;

3) наемга алучының яшәү урыныннан белешмә;

4) йорт (фатир) кенәгәсеннән торак бинада яшәүче затлар турында өземтә;

5) наемга алучының гаилә әгъзалары сыйфатында башка гражданнарны урнаштыру өчен, наемга алучының гаилә әгъзаларының, шул исәптән вакытлыча булмаган әгъзаларының язмача ризалыгы.

Документларны кабул иткәндә, гариза бирүчегә документларны кабул итү турында расписка бирелә.

12. Урнаштырганнан соң торак бинаның гомуми мәйданы гаиләнең бер кешесенә исәпләү нормасыннан ким туры килсә, наемга бирүче наемга алучы белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары сыйфатында башка гражданнарны урнаштыруга рөхсәт бирүдән баш тартырга хокуклы.

13. Ата-ана янына балигъ булмаган балаларын урнаштыру өчен гаиләнең башка әгъзаларының һәм наемга бирүченең ризалыгы таләп ителми.

## 3 бүлек. Социаль наем килешүе буенча биләнүче торак бинага наемга алучы тарафыннан икенчел наемга алучы сыйфатында башка гражданнарны урнаштыру

14. Социаль наем килешүе буенча бирелгән торак бинаны наемга алучы наемга бирүченең һәм үзе белән бергә яшәүче гаилә әгъзаларының язмача ризалыгы буенча үзләре биләгән торак бинаның бер өлешен бирергә, ә торак бинадан вакытлыча киткән очракта, аны тулысынча икенчел наемга тапшырырга хокуклы.

15. Социаль наем килешүе буенча бирелгән торак бинага икенчел наем килешүе, аны төзегәннән соң тиешле торак бинаның гомуми мәйданы бер кешегә исәпләү нормасыннан, ә коммуналь фатирда – бирү нормасыннан ким туры килмәү шарты белән төзелергә мөмкин.

16. Социаль наем килешүе буенча бирелгән торак бинага икенчел наем килешүе язма рәвештә төзелә. Социаль наем килешүе буенча бирелгән торак бинага икенчел наем килешүенең 1 нөсхәсе ул торак бинаны наемга бирүчегә тапшырыла.

17. Социаль наем килешүе буенча бирелгән торак бинага икенчел наем килешүендә торак бинаны икенчел наемга алучы белән бергә урнашкан гражданнар күрсәтелергә тиеш.

18. Социаль наем килешүе буенча бирелгән торак бинага икенчел наем килешүе әлеге килешүнең яклары билгеләгән срокка төзелә. Килешүдә срок билгеләнмәгән булса, килешү бер елга төзелгән санала. Торак бинага социаль наем килешүе туктатылу бер үк вакытта торак бинаны икенчел наемга алу килешүенең тукталуына китерә.

19. Торак бинаны наемга алучы үзе биләгән торак бинага икенчел наемга алучылар сыйфатында башка гражданнарны урнаштырырга теләгәндә, торакны үстерү бүлегенә социаль наем килешүе (ордеры) шартларында гражданнар тарафыннан биләнүче муниципаль торак бинага икенчел наемга алучылар сыйфатында башка гражданнарны урнаштыруга рөхсәт бирү турында Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә әлеге Нигезнамәнең 2 нче кушымтасында каралган форма буенча гариза тапшыра.

20. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) наемга алучының һәм торак бинада аның белән яшәүче затларның һәм торак бинага урнаштыру турындагы мәсьәләне карауга мөнәсәбәтле гражданның паспорт күчермәсе (торак бинада наемга алучы белән яшәүче ундүрт яшькә кадәрге балигъ булмаганнарның туу турында таныклык күчермәсе);

2) торак бинага социаль наем (ордерның) килешүенең төп нөсхәсе яки законда билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсе;

3) өч нөсхәдә икенчел наем килешүе;

4) торак бинага урнашучы гражданнарның авыр формадагы хроник авырулары (исемлеге Россия Федерациясе Торак кодексының 51 маддәсендәге таләпләр нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарның бер фатирда бергә яшәвенә комачаулаучы авыр формадагы хроник авыруларның исемлеген раслау турында» 2012 елның 29 ноябрендәге 987н санлы карары белән расланган) булмау турында медицина белешмәсе;

5) наемга алучының яшәү урыныннан белешмә.

Документларны кабул иткәндә, гариза бирүчегә документларны кабул итү турында расписка бирелә.

21. Гаризага наемга алучы, шулай ук торакны үстерү бүлеге белгече алдында, яисә имзаның дөреслеген нотариуста раслау юлы белән гаиләнең барлык әгъзалары, шул исәптән вакытлыча булмаган гаилә әгъзалары имза куя. Коммуналь фатирда урнашкан торак бүлмәне икенчел наемга биргәндә, гаризага шулай ук барлык наемга алучылар һәм алар белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары, барлык милек хуҗалары һәм алар белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары имза куя.

22. Икенчел наем килешүе яшәү урынына теркәлүне рәсмиләштерү өчен нигез булып тора.

23. Наемга бирүче түбәндәге очракларда торак бинаны (торак бинаның бер өлешен) икенчел наемга тапшыруга рөхсәт бирүне кире кагу турында карар кабул итә:

1) икенчел наем килешүе буенча гражданнарны (гражданны) урнаштырганнан соң, тиешле торак бинаның гомуми мәйданы бер кешегә исәплəү нормасыннан, ә коммуналь фатирда – бирү нормасыннан ким туры килгәндә;

2) икенчел наемга тапшырылучы торак бинада, Россия Федерациясе Торак кодексының 51 маддәсендәге 1 бүлекнең 4 пунктын күздә тотып, Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрыгының «Гражданнарның бер фатирда бергә яшәвенә комачаулаучы авыр формадагы хроник авыруларның исемлеген раслау турында» 2012 елның 29 ноябрендәге 987н санлы карары белән расланган исемлектәге авыр формадагы бер хроник авырулы граждан яшәгәндә яки урнашканда;

3) коммуналь фатирда булган торак урынын наемга бирү өчен барлык наемга алучыларның һәм аларның гаилә әгъзалары белән бергә яшәүчеләрнең һәм аларның гаилә әгъзалары белән бергә яшәүче милекчеләрнең ризалыгы булмаганда

24. Икенчел наемга алучы(лар) торак бинадан мөстәкыйль файдалану хокукына ия булмый. Торак бинага социаль наем килешүе буенча наемга бирүче алдында наемга алучы җаваплы булып кала.

## 4 бүлек. Социаль наем килешүе буенча биләнүче торак бинага наемга алучы тарафыннан вакытлыча яшәүчеләр сыйфатында башка гражданнарны урнаштыру

24. Социаль наем килешүе буенча тапшырылган торак бинаны наемга алучы һәм аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары, үзара килешеп һәм наемга бирүчегә алдан хәбәр итеп, социаль наем килешүе буенча биләнүче торак бинада вакытлыча яшәүчеләр сыйфатында башка гражданнарның түләүсез яшәвен рөхсәт итү хокукына ия.

25. Вакытлыча яшәүчеләрнең яшәү срогы берьюлы алты айдан артырга тиеш түгел. Вакытлыча яшәүчеләр тиешле торак бинадан мөстәкыйль

файдалана алмыйлар. Аларның гамәлләре өчен, наемга бирүче алдында наемга алучы җаваплы.

26. Социаль наем килешүе буенча биләнүче торак бинага наемга алучы тарафыннан вакытлыча яшәүчеләр сыйфатында башка гражданнарны урнаштырганда, наемга алучы торакны үстерү бүлегенә әлеге Нигезнамәнең 3 нче кушымтасында каралган форма буенча Башкарма комитет Җитәкчесе исеменә социаль наем килешүе шартларында гражданнар тарафыннан биләнүче муниципаль торак бинага вакытлыча яшәүчеләр сыйфатында башка гражданнарны урнаштыру турында гариза тапшыра:

27. Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) наемга алучының һәм торак бинада аның белән яшәүче затларның һәм торак бинага урнаштыру турындагы мәсьәләне карауга мөнәсәбәтле гражданның паспорт күчермәсе (торак бинада наемга алучы белән яшәүче ундүрт яшькә кадәрге балигъ булмаганнарның туу турында таныклык күчермәсе);

2) торак бинага социаль наем килешүенең (ордерның) төп нөсхәсе яки законда билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсе;

3) наемга алучының яшәү урыныннан белешмә.

Документларны кабул иткәндә, гариза бирүчегә документларны кабул итү турында расписка бирелә.

28. Наемга бирүче тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре нигезендә, гражданны урнаштырганнан соң, тиешле торак бинаның гомуми мәйданы һәр кешегә аерым фатирда исәпләү нормасыннан, ә коммуналь фатирда – бирү нормасыннан ким туры килгән очракта, наемга алучының социаль наем килешүе буенча биләнүче фатирга гражданны урнаштыруын кире кагарга хокуклы.

29. Яшәү өчен килешенгән срок үткәннән соң, ә срогы килешенмәгән очракта, наемга алучының яки аның белән бергә яшәүче гаилә әгъзаларының тиешле таләбе куелганнан соң җиде көн эчендә, вакытлыча яшәүчеләр тиешле торак бинаны бушатырга тиеш.

30. Торак бинага социаль наем килешүе туктатылган, шулай ук яшәү өчен килешенгән срок үткәннән соң яки әлеге Нигезнамәнең 28 пунктында күрсәтелгән таләп куелганнан соң, вакытлыча яшәүчеләр торак бинаны бушатудан баш тарткан очракта, алар суд тәртибендә, башка торак бирмичә, торак бинадан чыгарылырга тиеш.

## 5 бүлек. Торак биналарга урнаштырганда документларны рәсмиләштерү

31. Социаль наем килешүләре буенча биләнүче Яр Чаллы шәһәре муниципаль торак фондының торак биналарына наемга алучы белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары, икенчел наемга алучылар, вакытлыча яшәүчеләр сыйфатында башка гражданнарны урнаштыру турындагы мәсьәләне карауны торакны үстерү бүлеге гамәлгә ашыра.

32. Торак бинага урнашучы гражданнар, шулай ук күрсәтелгән гражданнарның урнашуына үз ризалыгын белдерүче затлар документларны тапшыралар һәм торакны үстерү бүлеге белгечләре катнашында урнаштыру турындагы гаризага имза куялар. Торакны үстерү бүлеге белгече гражданнарның имзаларын үз имзасы белән раслый.

Урнаштыруга ризалык белдерүче гражданның торак йортларны исәпкә алу идарәсенә килү мөмкинлеге булмаса, гаризада аның имзасы законда каралган башка ысул белән раслана.

33. Гаризаларны карaганда, торакны үстерү бүлеге белгечләре гариза бирүчеләр тарафыннан тапшырылган, хокукый актны кабул иткәндә юридик әһәмияткә ия мәгълүматларның дөреслеген тикшерергә хокуклы.

34. Наемга алучының гаризасын карау нәтиҗәләре буенча торакны үстерү бүлеге күрсәтелгән документлар тапшырылган көннән соң ун эш көне эчендә, Башкарма комитетның наемга алучы белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары сыйфатында гражданнарны урнаштыруга, икенчел наемга алучыларны урнаштыруга һәм муниципаль торак фондта вакытлыча яшәүчеләргә яшәү өчен рөхсәт бирү яисә әлеге рөхсәтне кире кагу турындагы карар проектын әзерли.

35. Наемга алучыларның урнаштыру турындагы гаризалары махсус журналда теркәлергә тиеш.

36. Наемга алучыларның урнаштыру турындагы гаризалары, алар буенча кабул ителгән хокукый актлар, шулай ук наемга алучылар тарафыннан тапшырылган барлык документлар гамәлдәге законнар нигезендә сакланырга тиеш.

37. Әлеге Нигезнамәгә туры китереп, Башкарма комитет тарафыннан кабул ителүче хокукый актлар, кабул ителгән көннән соң өч көн эчендә гариза бирүченең үзенә яки аның законлы вәкиленә тапшырыла.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы — Н.И. Галиева

Яр Чаллы шәһәре муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алучыларга урнашуга рөхсәт бирү тәртибе турында нигезнамәгә
1 нче кушымта

Башкарма комитет
Җитәкчесенә
______________________________
адрссы буенча яшәүче
______________________________
(гариза бирүченең Ф.И.А.и.)

Социаль наем (ордеры) килешүләре шартларында гражданнар тарафыннан биләнүче муниципаль торак бинага наемга алучы белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары сыйфатында башка гражданнарны урнаштыру турында гариза

______________________________________________________________
______________________________________________________________
(социаль наем (ордеры) килешүе: номеры, рәсмиләштерү датасы)
буенча минем тарафтан биләнүче торак бинага түбәндәге балигъ булган гражданнарны:

1. ___________________________________________________________
(Ф.И.А.и., паспорт: серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
2. ___________________________________________________________
(Ф.И.А.и., паспорт: серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

һәм (яки) балигъ булмаган балаларны:

1. ___________________________________________________________
(Ф.И.А.и., туу турында таныклык)
2. ___________________________________________________________
(Ф.И.А.и., туу турында таныклык)

торак бинадан /торак мәйданнан наемга алучы һәм аның гаилә әгъзалары белән бер үк дәрәҗәдә файдалану хокукын алучы гражданнар сыйфатында урнаштыруны документ нигезендә рәсмиләштерүне сорыйм.

Аларны урнаштырган очракта, һәр кешегә торак бина гомуми мәйданының ____ кв.м. туры киләчәк.

Гаиләмнең балигъ булган барлык әгъзалары да күрсәтелгән затларны урнаштыруга риза.

Урнаштыруга риза:

1. __________________________________________________ __________
(Ф.И.А.и., паспорт: серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) (имза)
2. __________________________________________________ __________
(Ф.И.А.и., паспорт: серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) (имза)

Имзаларны раслыйм: ____________________________________ __________
(белгечнең вазыйфасы һәм Ф.И.А.и.) (имза)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алучыларга урнашуга рөхсәт бирү тәртибе турында нигезнамәгә
2 нче кушымта

Башкарма комитет
Җитәкчесенә
___________________________________
адресы буенча яшәүче
___________________________________
(гариза бирүченең Ф.И.А.и.)

Социаль наем (ордер) килешүләре шартларында гражданнар тарафыннан биләнүче муниципаль торак бинага икенчел наемга алучы сыйфатында башка гражданнарны урнаштыру турында
гариза

_________________________________________________________________________
_________________________________________________________________________
(социаль наем килешүе: номеры, рәсмиләштерү датасы)
нигезендә минем файдалануга алынган торак бинага __________ елның №____ икенчел наем килешүе буенча түбәндәге балигъ булган гражданнарны:
1. _____________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., паспорт: серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
2. _____________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., паспорт: серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
балигъ булмаган балалары:
1. _____________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., туу турында таныклык)
2. _____________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., туу турында таныклык)
белән бергә икенчел наемга алучылар сыйфатында урнаштыруны рөхсәт итүне һәм документ нигезендә рәсмиләштерүне сорыйм.

Аларны урнаштырган очракта, һәр кешегә торак бина гомуми мәйданының ___ кв.м. туры киләчәк.

Гаиләмнең әгъзалары икенчел наемга алучыларны урнаштыруга риза.

Коммуналь фатирда минем белән бергә яшәүче башка наемга алучылар һәм алар белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары, башка милек хуҗалары һәм алар белән бергә яшәүче гаилә әгъзалары икенчел наемга алучыларны урнаштыруга риза. (Икенчел наемга алучыларны социаль наем (ордер) килешүе буенча биләнгән торак бинага урнаштырганда ризалык таләп ителә).

Икенчел наем килешүенең күчермәсен терким.

Гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ: төре ________________
(паспорт)
серия ______, № _________, _________________________ тарафыннан бирелгән.
(органның исеме)
«____» ____________201_ ел. Гариза бирүченең имзасы ____________________
«____» ____________201_ ел.

Урнаштыруга риза:

1. ____________________________________________________________ ________
(Ф.И.А.и., паспорт: серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) (имза)

2. ____________________________________________________________ ________
(Ф.И.А.и., паспорт: серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) (имза)

Икенчел наемга алучылар:

1. ____________________________________________________________ ________
(Ф.И.А.и., паспорт: серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) (имза)

2. ____________________________________________________________ ________
(Ф.И.А.и., паспорт: серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) (имза)

Имзаларны раслыйм: ____________________________________ ________
(белгечнең вазыйфасы һәм Ф.И.А.и.) (имза)

Яр Чаллы шәһәре муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алучыларга урнашуга рөхсәт бирү тәртибе турында нигезнамәгә
3 нче кушымта

Башкарма комитет
Җитәкчесенә
______________________________
адресы буенча яшәүче
______________________________
(гариза бирүченең Ф.И.А.и.)

Социаль наем килешүләре шартларында гражданнар тарафыннан биләнүче муниципаль торак бинага вакытлыча яшәүчеләр сыйфатында башка гражданнарны урнаштыру турында
гариза

____________________________________________________________
____________________________________________________________
(социаль наем килешүе: номеры, рәсмиләштерү датасы)
нигезендә минем файдалануга алынган торак бинага _________дан _________ га кадәр срокка түбәндәге балигъ булган гражданнарны:
1. ________________________________________________________
(Ф.И.А.и., паспорт: серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
2. ________________________________________________________
(Ф.И.А.и., паспорт: серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)
балигъ булмаган балалары:
1. ________________________________________________________
(Ф.И.А.и., туу турында таныклык)
2. ________________________________________________________
(Ф.И.А.и., туу турында таныклык)
белән бергә вакытлыча яшәүчеләр сыйфатында урнаштыруны рөхсәт итүне һәм документ нигезендә рәсмиләштерүне сорыйм. Вакытлыча яшәүчеләрнең яшәү срогы РФ Торак кодексының 80 маддәсендәге 2 бүлегендә каралганча, алты айдан арта алмый.

Аларны урнаштырган очракта, һәр кешегә торак бина гомуми мәйданының ____ кв.м. туры киләчәк.

Гаиләмнең әгъзалары вакытлыча яшәүчеләрне урнаштыруга риза.

Гариза бирүченең шәхесен раслаучы документ: төре ________________
(паспорт)
серия _______, № ____, __________________________________тарафыннан бирелгән.
(органның исеме)
«_____» ____________201_ ел. Гариза бирүченең имзасы ____________________
«_____» _____________201_ ел.

Урнаштыруга риза:

1. ________________________________________________ __________
(Ф.И.А.и., паспорт: серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) (имза)

2. ________________________________________________ __________
(Ф.И.А.и., паспорт: серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) (имза)

Вакытлыча яшәүчеләр:

1. ________________________________________________ __________
(Ф.И.А.и., паспорт: серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) (имза)

2. ________________________________________________ __________
(Ф.И.А.и., паспорт: серия, номер, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән) (имза)

Имзаларны раслыйм: ________________________________ __________
(белгечнең вазыйфасы һәм Ф.И.А.и.) (имза)